«Кошлар - безнең дуслар”

Максат:Хикәяне сәхнәләштерү аша аның эчтәлеген аңларга булышу;

Сүзлек запасын баету,тыңлый белү сәләтен үстерү.

Интеграция: Сөйләм телен үстерү.

Матур әдәбият.

Нәфасәти тәрбия.

Хезмәт.

Физик тәрбия.

Бурычлар:

1.Тәрбияләү бурычлары.Күзәтүчәнлек,кошларга карата сак караш,алар турында кайгыртучанлык,кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү.

2.Үстерү бурычлары Балаларның хәтер сәләтен,чагыштырып тасвирлый белү күнекмәләрен, күрсәтмә-образлы фикерләү сәләтен һәм үзара аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

Сүзлек өстендә эш;Җим,җимлек.

Алдангы эшчәнлек;

Саф һавада кошларны күзәтү.

Этиләр ярдәме белән җимлекләр ясау;

Дидактик уен;Безнең кошлар:

Җиһазлау;1”Балачак аланы”хрестоматия.Казан,2011

2Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы.Казан.2012.

3 “Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланма,Казан2013.

Балалар,әйдәгез эле килгән кунаклар белән исәнләшик.

-Исәнмесез.

-Хәзер матур итеп, урыннарга утырабыз.

-Балалар,мин сезгә бер табышмак эйтеп китәм тыңлагыз эле.

Тәңкә карлар сипкән

Җирне ап-ак иткән,

Чыршы каен,имән

Кардан матур тун кигән

Бу кайчан?(Кыш)

-Балалар,без сезнең белән җылы киенәбез,җылы бүлмәләрдә уйныйбыз,ашыйбыз,э менә кыш җиткәч,безнең кошларыбыз нишли икән,ничек уйлыйсыз?

-Аларга салкын,азык юк.

-Әйе балалар,аларга салкын,ашарга табу бик кыен.

-Кыш көне бездә нинди кошлар яшиләр?

-Чыпчыклар,күгәрченнәр,песнәкләр,ала каргалар,саесканнар.

-Дйрес.Ә менә мин сезгә бүген бер булган вакыйга турында сөйләп китмәкче булам,игътибар белән тыңлап утырыгыз.(Сәхнәләштерү.)

Кышкы көн иде.Көннәр үтә салкынаеп китте.Суык бабай стеналарга шарт-шарт итә.Тышка чыксаң борынны чеметә.Кошларныңда хәле бик аврайды.Аларга ашарга табу кыенлашты.Беркөнне Әнисәнең тәрәзәсенә сары түшле песнәк килеп кунды.Тәрәзә пыяласын чукырга тотынды.

-Әни,әни бер кош безнең тәрәзәне чукый.

-Бу песнәк кызым, күрәсеңме тышта салкын,аның ашыйсы килә,җирләрне кар каплаган ул үзенә азык таба алмаган.

-Кызым аңа җим бирергә кирәк,җим!

-Әни нәрсә соң ул җим?

-Кызым без синең белән ипи,май,аш ашыйбыз,ә кошлар,ипи валчыклары,ярма бөртекләзе,туңмай болар барысыда җим дип атала.Кошларга безнинди генә азык бирсәктә ул җим була.

-Алайса,тизрәк аңа җим бирик аны ашатыйк ә кая салабыз җимне әни?

-Кызым без синең белән савыттан ашыйбыз,ә кошлар җимлектән ашыйлар.Менә әтиең кичә матур җимлек ясады,сал кызым җимне җимлеккә.Әнисә тиз генә ипи валчыклары сиптте.Песнәк бик шатланды,ашап бетергәч канат кагып,Әнисәгә рәхмәт әйтте.Шул көннән алып ,песнәк Әнисәнең тәрәзә төбенә ияләшеп китте,җим биреп песнәкне ашатты,ә песнәк үзенчә аңа рәхмәт әйтеп, сайрый торгон булды. Ә песнәк тора бара ачык тәрәзәдән өйгә дә керә башлады.Шулай итеп алар бик дуслаштылар.

-Сезгә ошадымы балалар?

-Әйе.

-Балалар Әнисәнең тәрәзәсенә нинди кош килгән?

-Сары түшле песнәк.

-Әйе бик дөрес,песнәк очып килгән.

-Кем әйтә,ни өчен песнәк тәрәзә янына килгән?

-Чөнки аның ашыйсы килгән,туңган өшегән,ул үзенчә кешеләрдән ярдәм сораган.

-Дөрес балалар,ә Әнисә ярдәм иткәнме песнәккә?

-Әйе.

-Нишләгән Әнисә?

-Песнәккә җим биргән.

-Ә песнәк нишләгән?

-Рәхмәт әйткән.

-Балалар,әйдәгез әле бераз ял итеп алыйк.

- (уен “Песнәк”.Бер бала сайлана.)

Песнәк, песнәк әйт әле ничек чыпчык сикерә?

Менә болай менә шулай чыпчыклар сикерә. (сикерәләр)

Песнәк,песнәк әйт әле ничек үрдәкләр йөри

Менә болай менә шулай ,үрдәкләр йөри(чүгәләп йөриләр)

Песнәк песнәк әйт әле ничек песнәкләр оча,

Менә болай менә шулай песнәкләр оча.

-Менә бераз ял итеп уйнап алдык
Слайд;-балалар безнең мәйданчыкка нинди кошлар киләләр,рәсемннән карап эйтеп китик әле.

-Песнәк,чыпчык,күгәрчен,саескан,ала карга.

-Балалар ,кыш көнендә кошларга безнең ярдәм кирәк,без аларга ничек итек ярдәм итә алабыз?

-Җим бирәбез.

Слайд;Рәсемгә карыйк әле ,нинди җимнәр бирергә була.(ярма бөртекләре,ипи валчыклары,туңмай)

-Ә җимне кая салабыз?

-Җимлеккә.

Слайд;-Әйе җимлеккә салабыз,рәсемгә күз салыйк әле нинди җимлекләр булалар.

-Балалар карагыз әле менә бу рәсемгә,монда безнең , агачлар,буш җмлекләр тора,эйдәгез әле бергәләп,кошларны ашатыйк,җим сибик,нинди кошлар очып килер микән.

(Күмәк эш,буш җимлек рәсеменә җимнәр ясау,берничә кош ябыштырып чыгу)

-Булдымы балалар,әйдәгез әле рәсемне карап китик.кошлар очып килгәнме безнең җимлеккә?

-Әйе.

-Ә ни өчен очып килгәннәр икән ничек уйлыйсыз?

-Чөнки без аларга җим салдык.

-Әйе балалар,безнең җимлек янына бик күп кошлар очып килделәр,алар сезгә рәхмәт әйтәләр.Сезгә бүгенге эшчәнлек ошадымы балалар,нәрсә күбрәк ошады.

-Кошларны ашату,Әнисәнең пенәккә булышуы һ.б.

-Димәк ,кыш көне без кошларга ярдәм итәргә,аларны ашатырга.сакларга,якларга тиешбез.

-Рәхмәт сезгә балалар,ә инде урамга чыкканда без сезнң белән чын кошларга җим бирербез,аларны күзәтербез.